**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАРЫ**

**2021 елның 4 май** **№ 37**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә «Муниципаль-хосусый партнерлык турында нигезләмә» 2017 елның 19 апрелендәге 90 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында** ***(2020 елның 22 июнендәге 261 номерлы карар редакциясендә)***

«Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2017 елның 19 апрелендәге 90 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль-хосусый партнерлык турында Положениегә (22.06.2020 № 261 үзгәрешләр белән .) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3 пунктчада «аларның инфраструктурасы объектлары, шул исәптән ясалма җир кишәрлекләре, порт гидротехник корылмалары» сүзләрен өстәргә;"

түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

«13) алкогольле, наркотик яисә башка токсик исерек затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмалар объектлары.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.А. Габидуллинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе** **Н.А. Вазыйхов**